# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Арбузов Баран авылы

11 ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Арбузов Баран торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1.2021 елда Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә Арбузов Баран авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту кышын һәм җәен(кардан чистарту һәм үләннәр чабу);
- буаны төзекләндерү(бульдозер хезмәтләре) ;
- җирләү урыннарын төзекләндерү( рәшәткә өчен кирәк-ярак сатып алу).

3.Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Арбузов Баран авыл клуб бинасының мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин